

11 октябрьдә Матбугат йортында «Район судларында присяжный заседатель - хокемче институтын куллану» («Применение института присяжных заседателей в районных судах»)  темасын ачыклаган түгәрәк остәл үтте. Журналистлар белән Мордовия Югары һәм район судлары хокемдарлары, муниципаль администрация житәкчеләре, прокуратура халкы, адвокатура һәм фән кешеләре катнашты.

Киләсе елга Россиядә присяжный судлар янача хезмәт итәр. Ә 2018нче елнын июненнән региональ присяжный заседательләр саны 12дән 8 кадәр кыскартылыр, шул ук вакытта присяжныйлар институты районнарда барлыкка килер. Яналыклар бу системанын эшен камилләштерүгә багышланган; закондагы тогәлсезлекләрне тозәтү максаты белән эшләнә.       Югары суд присяжныйлары командасын оештыруда кыенлыклар бар, ә районнарга килгәндә - эш тыгызлана. Күп кенә кешеләр бу жаваплы вазыйфаны үтәргә әзер түгелләр, ди түгәрәк остәлне алып барган Сергей Валентинович Штанов, Мордовия Республикасы Югары Суд председателе. Анын урынбасары Сюбаев Ильдар Ислям улы, присяжный заседательләрнен списогын булдырганда килеп чыккан авырлыклар һәм аларны сайлау кагыйдәләренә тукталды. Анда 25 яшьтән кече булмаган, әлегә кадәр жавапка тартылмаган, психик яктан нык һәм башка унай сыйфатлы кеше сайланырга тиеш, ди. Районнарда шундыйларны табу проблемага әйләнә, икән.

Калган катнашучылар район судларында присяжный заседатель - хокемче институтын булдыру нечкәлекләре турында бәян иттеләр.